ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

09.04.2019 № 318

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы бюджетыннан җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2010 ел, 28 март, 233 нче карарына таянып, һөнәри керемгә салым буенча салым потенциалы үсешен стимуллаштыру максатларында

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы бюджетыннан җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга (1 нче кушымта).
2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Нурлат муниципаль районы финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесе рәисенә йөкләргә (килешү буенча).

Җитәкче Л.Н. Маняпов

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының

2019 ел, 9 апрель, 318 нче

карары белән расланды

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы бюджетыннан җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү механизмын билгели (алга таба – башка бюджетара трансфертлар, муниципаль берәмлекләр).

2. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасында профессиональ керемгә салым буенча салым потенциалы үсешен стимуллаштыру максатларында Нурлат муниципаль районы җирлекләре бюджетларына җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә бирелә.

3. Башка бюджетара трансфертлар тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы бюджеты турында карарында каралган бюджет ассигнованиеләре күләме чикләрендә узган кварталдан соң килүче айның 30 числосына кадәр җирлекләр бюджетларына бирелә.

4. Әлеге Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчаларын төп бүлүче булып «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесе (алга таба – финанс-бюджет Палатасы) тора.

5. Башка бюджетара трансфертларны бүлү Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

6. i-нче муниципаль берәмлек өчен тиешле кварталның башка бюджетара трансфертлар күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$МТ_i^{кв} = НПД_i^{ел} – НПД_i^{пт},$$

монда

$МТ_i^{кв}$ - тиешле квартал өчен i - муниципаль берәмлегенә башка бюджетара трансфертлар күләме, сум;

$НПД_i^{ел}$ - Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы бюджетына i муниципаль берәмлек территориясеннән кергән һөнәри керемгә салым суммасы Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә теркәлгән салым түләүдән ел башыннан арта бара торган салымнан, сум;

$НПД_i^{пт}$ - элек башка бюджетара трансфертлар бирү максатларында исәпкә алынган Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә теркәлгән салым түләүчеләрдән i муниципаль берәмлек бюджетына кергән һөнәри керемгә салым суммасы, сум.

7. Муниципаль район составына керүче җирлекләр бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү шарты булып җирлекнең башка бюджетара

трансфертлар акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган чыгымнарның юнәлешен билгели торган норматив хокукый акты булу тора.

8. Башка бюджетара трансфертлар финанс-бюджет палатасы тарафыннан җирлекләр бюджетларына җирле бюджетларның үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен ачылган Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең территориаль органнары счетына күчерелә.

9. Җирлекләрнең башкарма комитетлары (алга таба – җирлек башкарма комитетлары) финанс-бюджет палатасына форма буенча һәм финанс-бюджет палатасы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисап тапшыралар.

10. Агымдагы финанс елның 1 гыйнварына әлеге Тәртип нигезендә алынган башка бюджетара трансфертлар агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Финанс-бюджет палатасы тарафыннан хисап финанс елында файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларга ихтыяҗ булу турында карар нигезендә әлеге башка бюджетара трансфертларның калдыкларыннан артмаган күләмдә акчалар агымдагы финанс елында җирлек бюджеты керемнә кире кайтарылырга мөмкин, моңа кадәр алар бирелгән җирлек бюджеты чыгымнарын финанс ягыннан тәэмин итү өчен, әлеге башка бюджетара трансфертлар бирүнең тиешле максатларына туры килә торган җирлек бюджеты керемнә кире кайтарылырга мөмкин.

Әлеге Тәртип нигезендә алынган башка бюджетара трансфертларның файдаланылмаган калдыклары Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы бюджеты керемнә күчерелмәгән очракта, әлеге акчалар Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы бюджеты керемнә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, финанс-бюджет палатасы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә түләтелергә тиеш.

11. Җирлекләр башкарма комитетлары һәм вазыйфаи затлар законнар нигезендә тапшырыла торган хисап мәгълүматларының дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын үтәү өчен җаваплы.

12. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары бозылган очракта, тиешле акчалар Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы бюджеты керемнә Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә күчерелергә тиеш.

13.Әлеге Тәртип нигезендә бирелгән башка бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын финанс-бюджет палатасы контрольдә тота.